| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
| --- | --- | --- |
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 13.12.2018 | Баулы шәһәре | № 187 |

Баулы муниципаль районы Советының
2014 елның 19 маенда кабул ителгән
«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль
районы территориясендә тышкы реклама
һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру
тәртибе турындагы нигезләмәне раслау
хакында" 212 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында»

"Реклама турында" Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 3 июлендәге 183-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 19 маенда кабул ителгән 212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әгәр мөрәҗәгать итүче тиешле күчемсез мөлкәтнең хуҗасы яисә аның башка законлы хуҗасы булып тормаса, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) региональ порталларын файдаланып, язмача яисә электрон документ формасында, әлеге мөлкәткә реклама конструкциясен куюга аның ризалыгын раслау»;

7.13 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) Реклама конструкциясе хуҗасы рөхсәтне алга таба кулланудан баш тарту турында язма белдерү кәгазе яки электрон документ формасында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып, Башкарма комитетка җибәргән көннән алып бер ай эчендә”

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе

Р.Х. Гатиятуллин